| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.11.2022 г. Казань № 3006

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 14.12.2018 № 2753 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р а м:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 14.12.2018 № 2753 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 17.03.2020 № 480 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

пункт 2 түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Фармация идарәсенең дару тәэминаты белән идарә итү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Фармация идарәсенең дару чаралары әйләнеше өлкәсендә җайга салу бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Фармация идарәсенең дәүләт заказын җайга салу бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

медицина техникасы бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

Лицензияләү идарәсенең медицина эшчәнлеген лицензияләү буенча бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

бюджеттан тыш сәламәтлек саклау секторының әйдәп баручы консультанты;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген координацияләү һәм контрольдә тоту секторының әйдәп баручы консультанты;

сәламәтлек саклауның ресурслар тәэминатын мониторинглау һәм анализлау секторының әйдәп баручы консультанты;

Казан шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең ананың һәм баланың сәламәтлеген саклау бүлеге консультанты».

Министр М.Н.Садыков

Г.Р.Накипова
(843) 231-79-15